| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ПОПОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ПОПОВКА<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.05.2024 г. с.Поповка № 109

Вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында
Баулы муниципаль районының «Поповка авыл җирлеге» муниципаль
берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Поповка авыл җирлеге Уставы, Поповка авыл җирлеге советы КАРАР:

1. Баулы муниципаль районы советына Баулы муниципаль районы башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Баулы авыл җирлеге башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү һәм аның эшчәнлек тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү.

2. Баулы муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне Баулы муниципаль районының Поповка авыл җирлеге башкарма комитетына кабул иткән очракта:

Баулы муниципаль районы башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Баулы муниципаль районы Попов авыл җирлеге Советының 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Поповка авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга

үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет башлыгы, рәисе С.А.Попов